**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 28 » гыйнвар 2026 ел** **№ 3**

**“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2025 елның 21 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2025 елның 21 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2026 елның 10 февралендә 17 сәг.00 минутта Арча районы, Төбәк-Чокырча авылы, Ленин урамы, 17а йорты адресы буенча билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында гражданнар жыены нәтижәләре турында» 2025 елнын 21 ноябрендәге 5 номерлы карарында гражданнар жыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, 1 төркем инвалидлар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне,

мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итүдән тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төбәк-Чокырча авылынын урамнарында юл өслегенең түшәмә катламын төзү)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Төбәк-Чокырча авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2025 елның 21 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Арча шәһәре башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урында мәгълүмат стендында (Төбәк-Чокырча авылы, Ленин урамы, 17а йорты), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башлыгы в.б. «Совет города Арск» Г.Х.Нигмәдҗанова